ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2019 с.Старое Дрожжаное № 140

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасының исемен үзгәртү хакында

Муниципаль бюджет учреждениеләренең эффектлы эшчәнлеген оптимизацияләү максатында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасының исемен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет оешмасы итеп үзгәртергә.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет оешмасында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасының эшчәнлек максатлары һәм төрләре саклана дип билгеләргә.
3. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет оешмасының Уставын расларга.
4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет оешмасы директорына гамәлдәге законнар нигезендә салым органнарында дәүләт теркәве узар өчен документлар тапшыру вакытында гариза бирүче вәкаләтләрен тапшырырга.
5. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 13 август № 395 карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазифаларын башкаручы: И.Р. Измайлов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
25 03 2019 ел № 140
карары белән расланган

# Татарстан Республикасы
# Чүпрәле муниципаль районы
# ”Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет оешмасы
# У С Т А В Ы

(яңа редакциядә)

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы**
**“Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе”**
**өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы**
**У С Т А В Ы**

(иске редакциядә)

Иске Чүпрәле авылы - 2019

# I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Устав Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы ”Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет оешмасы (алга таба – Оешма) эшчәнлеген җайга сала.

1.2. Оешманың тулы рәсми исеме:

рус телендә: муниципальная бюджетная организация «Спортивная школа» Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан;

татар телендә: Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет оешмасы.

Оешманың кыскартылган исеме: МБО «Спорт мәктәбе».

1.3. Оешманы гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы “Чүпрәле муниципаль районы” муниципаль берәмлеге исеменнән вәкаләтле орган - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты.

1.4. Оешманың милке һәм ул урнашкан җир кишәрлегенең милекчесе - “Чүпрәле муниципаль районы” муниципаль берәмлеге.

1.5. Оешма дәүләт теркәве узган моменттан юридик зат булып санала, үзенең аерымланган милкенә, мөстәкыйль балanска, финанс органнарында исәп-хисап счетларына, үз исеме төшерелгән мөһергә, эмблемага, бланкларга ия.

1.6. Оешма үз исеменнән милек хокукы һәм милеккә булмаган хокук алырга һәм гамәлгә ашырырга, йөкләмәләр алырга, судларда дәгъвачы һәм җавап бирүче буларак катнашырга хокуклы.

1.7. Оешма билгеләнгән тәртиптә исәп-хисап счетлары ачырга хокуклы.

1.8. Оешма үз йөкләмәләре буенча үзендә оператив идарәдә булган, Оешмага Милекче тарафыннан беркетелгән яки табыш китерүче эшчәнлектән килгән табыш бәрабәренә сатып алынган барлык милек белән, Оешмага Милекче тарафыннан беркетелгән яки Оешма тарафыннан аңа шундый милек алыр өчен Гамәлгә куючы бүлеп биргән акчага сатып алынган аеруча кыйммәтле күчмә милектән, шулай ук күчемсез милектән кала, җавап бирә.

1.9. Оешма, хәрби бурычлы затларны хәрби исәпкә алу турындагы законнарга һәм хәрби идарәнең җирле органнары таләпләренә таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән мобилизацион бурычларны үтәү буенча җавап тота, гражданлык оборонасы турындагы гамәлдәге законнар куйган таләпләрне үти.

1.10. Оешма, үз компетенциясе чикләрендә, дәүләт сере булып саналган мәгълүматны саклауны тәэмин итә. Оешмада дәүләт сере булып саналган мәгълүматны саклау өчен җаваплылык директорга йөкләнә.

1.11. Оешманың урнашу урыны һәм юридик адресы: 422470, Татарстан Республикасы, Иске Чүпрәле авылы, Дзержинский урамы, 36А йорт.

1.14. Түләүсез тренировка дәресләре уздырылучы биналарның урнашу урыннары адреслары:

1.14.1. 422478, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Алешкин-Саплык авылы, Мәктәп ур., 8 йорт.

1.14.2. 422481, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Городище авылы, Цеткин ур., 2а йорт.

1.14.3. 422472, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Түбән Каракитә авылы, Мәктәп ур., 1 йорт.

1.14.4. 422480, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чокалы авылы, Коминтерн ур., 12 йорт.

1.14.5. 422485, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Чуваш Чүпрәлесе авылы, Мәдәният ур., 5 йорт.

1.14.6. 422465, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Хорновар-Шигали авылы, Горький ур., 4 йорт.

1.14.7. 422482, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы,, Зур Аксу авылы, Октябрь ур., 47 йорт.

1.14.8. 422464, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Уби авылы, Кызыл мәйдан ур., 48 йорт.

1.14.9. 422464, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Яңа Уби авылы, Тынычлык ур., 7 йорт.

1.14.10. 422474, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы,, Шланга авылы, Ленин ур., 26 йорт.

1.14.11. 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Көньяк ур., 5 йорт.

1.14.12. 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Ш. Мөдәррис ур.,2А йорт.

1.14.13. 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Дементьев ур., 4 йорт.

1.14.14. 422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Дзержинский ур. 36А йорт.

## II. ОЕШМА ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, ПРЕДМЕТЫ ҺӘМ ТӨРЛӘРЕ

2.1. Оешма эшчәнлегенең максатлары физик культураны һәм халыкның төрле төркемнәре арасында массакүләм спортны үстерүдән, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары составына керә алырлык югары классլы спортчылар әзерләүдән гыйбәрәт.

2.2. Оешманың бурычлары:

Татарстан Республикасы һәм Россия җыелма командалары составына керергә мөмкинлек бирүче югары тотрыклы нәтиҗәләргә ирешү өчен махсуслаштырылган спорт буенча хәзерләнүгә оптималь санда перспективалы спортчыларны тарту;

спорт белән системалы шөгыльләнүгә максималь мөмкин булган санда кызыксынучыларны тарту;

спортчыларда физик, мораль-этика, ихтыярлылык сыйфатлары тәрбияләү;

шөгыльләнүчеләрнең сәламәтлеген ныгыту;

спортчыларның физик әзерлек дәрәҗәсен һәм спорттагы нәтиҗәләрен үстерү;

яшьләр арасында бозык гадәтләргә һәм хокук бозуларга каршы профилактика.

2.3. Оешма эшчәнлегенең предметы хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт сферасында Оешма төзелүнең максатларына ирешүгә юнәлтелгән эшләр башкару буенча эшчәнлегеннән гыйбәрәт.

2.4. Оешма эшчәнлегенең төп төре булып “Физик культура һәм спорт” тора.

Оешма үз эшчәнлегенең төп төренә туры китереп, законнарда билгеләнгән тәртиптә муниципаль бирем кысаларында түбәндәге хезмәтләрне һәм эшләрне башкара:

футбол, йөзү, көрәш, хоккей, чаңгыда узышлар, бадминтон, өстәл теннисы, ирекле көрәш, бокс буенча спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру;

спорт әзерлеге узучы затларның спорт ярышларында катнашуын тәэмин итү;

җыелма спорт командаларының спорт ярышларында катнашуын тәэмин итү;

медик-тернәкләндерү (реабилитация) чаралары, тестлаштыру, тирәнтен медицина тикшерүе үткәрү;

чикләнгән вакыт эчендә ирекле файдалану өчен ябык спорт объектларына керү мөмкинлеген тәэмин итү;

обеспечение доступа к закрытым спортивным объектам для свободного пользования в течение ограниченного времени;

спорт-сәламәтлендерү этабын оештыру һәм үткәрү.

организация и проведение спортивно-оздоровительного этапа.

2.5. Муниципаль биремнәр нигезендәге эшчәнлектән тыш, гражданнар һәм юридик затлар өчен федераль законнар билгеләгән тәртиптә Оешма үз ихтыяры белән аның төп эшчәнлегенә кагылышлы түләүле һәм охшаш хезмәтләр күрсәткәндә бердәй шартларда эшләр башкарырга, хезмәт күрсәтергә хокуклы, шул исәптән:

а) муниципаль биремнән тыш башкарылганда 2.4 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәтләр (эшләр);

б) эшчәнлекнең төп төрләре чикләрендә муниципаль хезмәтләр исемлегенә кермәгән, өстәмә муниципаль хезмәтләр булып торган хезмәтләр.

2.6. Оешма эшмәкәрлек эшчәнлеген һәм башка табыш китерүче эшчәнлекне, әгәр алар Оешма төзелгәндә куелган максатларга ирешүгә булышлык итсә, гамәлгә ашыра ала.

2.7. Эшчәнлекнең төп төрләрен гамәлгә ашыру кысаларында Оешма түбәндәге функцияләрне башкара:

2.7.1. Әзерлек этапларында спорт төрләре: футбол, йөзү, көрәш, хоккей, чаңгыда узышлар, бадминтон, өстәл теннисы, ирекле көрәш, бокс буенча спорт әзерлеге программаларын төзү, раслау һәм гамәлгә ашыру.

2.7.2. Эшче программалар, укыту планнары, календарь укыту графиклары, башка компонентлар, шулай ук бәяләүче һәм методик материаллар әзерләү һәм раслау.

2.7.3. Спортчыларны шәхси әзерләү планнарын төзү һәм раслау.

2.7.4. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының физкультура һәм спорт чаралары Бердәм календарь планына кертелгән чараларны гамәлгә ашыру.

2.7.5. Физик культура һәм спорт буенча дәресләр үткәрү.

2.8. Оешма өчен муниципаль биремнәр Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Оешма эшчәнлегенең әлеге Уставта күздә тотылган төп төрләренә туры китереп, формалаштырыла һәм раслана.

## III. ОЕШМАНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

3.1. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары билгеләгән тәртиптә Оешма хокуклы:

3.1.2. Юридик һәм физик затлар белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Оешма эшчәнлегенең максатларына, предметына, төрләренә каршы килмәүче килешүләр төзергә.

3.1.3. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Уставта билгеләнгән максатларга туры китереп, үз эшчәнлегенең эчтәлеген һәм конкрет формаларын билгеләргә.

3.1.4. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә, Гамәлгә куючы белән килештереп, Оешма эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәк булган структур бүлекчәләр төзергә.

3.1.5. Оешма дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар белән барлык сфераларда да мөнәсәбәтләрне шартнамәләр, килешүләр, контрактлар нигезендә төзи.

3.1.6. Гамәлгә куючы белән килештереп Оешма эшчәнлеген планлаштырырга һәм үсеш перспективаларын билгеләргә.

3.1.7. Спорт хәзерлеген материаль-техник тәэмин итүне, биналарны спорт әзерлегенең федераль стандартларына туры китереп җиһазлауны гамәлгә ашырырга.

3.1.8. Үзтикшерү үткәрергә, спорт әзерлеге сыйфатын бәяләүнең эчке системасы эшчәнлеген тәэмин итәргә.

3.1.9. Методик эш оештырырга, шул исәптән конференцияләр, семинарлар оештырырга һәм үткәрергә.

3.1.10. Оешма халыкка, предприятиеләргә, учреждениеләр, оешмаларга өстәмә түләүле хезмәт күрсәтергә хокуклы. Түләүле хезмәтләр җирле бюджет акчасына финанслануչы спорт мәктәбенең төп эшчәнлеге урынына күрсәтелергә тиеш түгел.

3.2. Оешма Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Оешма эшчәнлегенең максатларына һәм предметына каршы килмәгән башка хокукларны гамәлгә ашыра.

3.3. Оешма бурычлы:

3.3.1. Гамәлгә куючы тарафыннан формалаштырылган һәм расланган муниципаль биремне үтәргә.

3.3.2. Оешма хезмәткәрләре өчен куркынычсыз хезмәт шартлары булдыру һәм аларны социаль яклауны гамәлгә ашыру; спорт әзерлегенең куркынычсыз шартларын булдыру буенча чаралар күрергә.

3.3.3. Гамәлдәге законнар һәм Оешманың тиешле локаль акты нигезендә Оешма эшчәнлеге турындагы мәгълүматның ачык булуын тәэмин итәргә.

3.3.4. Оешма биналарындагы милекне һәм матди кыйммәтләрне саклауны тәэмин итәргә.

3.3.5. Оешма хезмәткәрлеренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итәргә.
3.3.6. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә оешма спортчыларына спорттагы исемнәр һәм спорт разрядлары бирүне тәэмин итәргә.

3.3.7. Спорт әзерлегенең федераль стандартлары таләпләрен үтәргә.

3.3.8. Сайланган спорт төре (спорт дисциплинасы) буенча тренер (тренерлар) җитәкчелегендә кешенең спорт әзерлеге программаларына туры килгән сыйфатлы һәм тулы спорт әзерлеге үтүен тәэмин итәргә.

3.3.9. Спорт әзерлеге үтүчеләрнең медицина тәэмин ителешен гамәлгә ашырырга.

3.3.10. Спортта допинг куллануны кисәтү һәм аның белән көрәш чараларын гамәлгә ашырырга, шул исәптән ел саен спорт әзерлеге узучылар белән дәресләр үткәрергә, анда аларга спортта допинг куллануның спортчы сәламәтлегенә зыяны, допингка каршы кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылык хакында мәгълүмат җиткерергә.

3.3.11. Спорт әзерлеге үтүчеләрне спорт әзерлеге узу, спорт төрләре буенча допингка каршы кагыйдәләр, шулай ук Оешманың эчке тәртип кагыйдәләре белән бәйле локаль норматив актлар белән таныштырырга.

3.3.12. Спорт әзерлеге үтүчеләрне һәм аларның тренерларын спорт чараларында, шул исәптән рәсми спорт ярышларында, катнашу өчен җибәрергә.

3.4. Оешма үзенә кергән акчалар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначейство Департаментында ачылган исәп-хисап счеты аша законнарда билгеләнгән тәртиптә операцияләр үткәрә.

3.5. Муниципаль биремнәрне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидияләр формасында гамәлгә ашырыла. Россия Федерациясе Бюджет кодексына туры китереп Оешмага башка максатлар өчен дә субсидияләр бирелергә мөмкин.

3.6. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Уставка һәм Оешманың локаль норматив актларына туры китереп Оешма башка бурычлар үти.

3.7. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп Оешма үз компетенциясе чикләрендә мөнәсәбәтләрне җайлаучы нормаларны үз эченә алган локаль норматив актлар кабул итә.

3.8. Оешмада сәяси партияләрнең, сәяси җәмәгать хәрәкәтләренең, дини берләшмәләрнең һәм алар гамәлгә куйган оешмаларның оештыру структураларын төзү һәм аларның эшчәнлеге тыела.

## IV. ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫНЫҢ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

4.1. Оешманы Гамәлгә куючының компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

а) Оешманы төзегәндә, үзгәртеп төзегәндә, тибын үзгәрткәндә һәм гамәлдән чыгарганда Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәү;

б) Оешманың Уставын һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне раслау;

в) Оешманың җитәкчесен билгеләү (раслау) һәм аның вәкаләтләрен туктату;

г) Оешма җитәкчесе белән хезмәт килешүе төзү һәм аны өзү;

д) Оешма Уставында каралган эшчәнлекнең төп төрләренә туры китереп юридик һәм физик затларга муниципаль хезмәт күрсәтүгә (эш башкаруга) муниципаль бирем формалаштыру һәм раслау;

е) Оешмага Милекче тарафыннан беркетелгән яки Оешма тарафыннан милек сатып алуга бирелгән акчага сатып алынган аерым кыйммәткә ия күчемле милекнең төрләрен һәм исемлеген билгеләү;

ж) Оешманың “Коммерциячел булмаган оешмалар турында” гы к Федераль законның 9.2 маддәсе 13 пунктында күздә тотылган критерийларга туры килгән эре килешүләр, күчемсез һәм аерым кыйммәткә ия күчемле милек белән килешүләрдән кала, төзүен алдан килештерү;

з) Оешма катнашында Оешманың “Коммерциячел булмаган оешмалар турында” гы к Федераль законның 27 маддәсендә билгеләнгән критерийлар буенча мәнфәгатьләренә туры китереп төзелгән килешүләрне, күчемсез һәм аерым кыйммәткә ия күчемле милек белән килешүләрдән кала, хуплау хакында карар кабул итү;

и) Оешма эшчәнлеге төрләренә караган, муниципаль биремнән тыш башкарылган хезмәтләр (эшләр) өчен, шулай ук муниципаль бирем кысаларында федераль законнарда билгеләнгән очракларда физик һәм юридик затлар тарафыннан түләү тәртибен билгеләү;

к) Оешма эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы һәм аңа беркетелгән муниципаль милектән Россия Федерациясе Финанс Министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләргә туры китереп файдалану турындагы хисапны төзү һәм раслау тәртибен билгеләү;

л) законнарда билгеләнгән очракларда коммерциячел булмаган оешмаларга аларны гамәлгә куючы яки катнашучы сыйфатында акча

средстволары (әгәр акча тапшыруның шартлары башканы күздә тотмаса) һәм башка милекне (Оешмага Милекче тарафыннан беркетелгән яки Оешма тарафыннан милек сатып алуга бирелгән акчага сатып алынган аерым кыйммәткә ия күчемле милектән кала), шулай ук күчемсез милекне тапшыруны килештерү;

м) муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итү;

н) гамәлдәге законнарда каралган таләпләргә туры китереп Оешманың финанс-хуҗалык планын төзү һәм раслау тәртибен билгеләү;

о) Оешманың кредитор бурычларының соңгы чиктәге, ягъни шуннан артып китү Оешма җитәкчесе белән хезмәт килешүе эш бирүче инициативасы белән Россия Федерациясе Хезмәт кодексына туры китереп өзелүгә китерүче, зурлыгын билгеләү;

п) гамәлдәге законнар нигезендә Оешма эшчәнлегенә контрольне гамәлгә ашыру;

р) милекне яңадан бүлгән чакта бюджет учреждениесеннән баланс бәясе 200 мең сумга чаклы булган (авторанспорттан кала) күчемле милекне алу турында карар кабул итү;

с) милекне яңадан бүлгән чакта бюджет учреждениесенә баланс бәясе 200 мең сумга чаклы булган (авторанспорттан кала) күчемле милекне беркетү турында карар кабул итү;

т) Гамәлгә куючының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.

## V. ОЕШМА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ

5.1. Оешма белән идарә итү федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларына һәм әлеге Уставка туры китереп шәхси идарә һәм коллегиальлек принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Оешманың шәхси башкарма идарәчесе булып Оешма директоры тора.

Оешманың идарәче коллегиаль органнары булып Гомуми җыелыш, Оешманың тренерлар Советы тора.

5.2. Җитәкченең (алга таба “Директор” дип исемләнә) компетенциясенә законнарда яки Оешма Уставында каралган мәсьәләләр керә.

5.3. Оешма Директоры үз эшчәнлеген Директорның хокуклары, бурычлары, җаваплылыгы, аның хезмәтенә түләү шартлары, килешүнең сроклары, эштән азат ителү шартлары билгеләнгән, Гамәлгә куючы белән төзелгән хезмәт килешүе нигезендә гамәлгә ашыра.

5.4. Оешма Директоры Оешма белән агымдагы җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм үз эшчәнлеге буенча Гамәлгә куючыга хисап бирә.

5.5. Оешма Директоры Спорт мәктәбе исеменнән ышанычнамәсез эш итә, аның мәнфәгатьләрен Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә кайгырта, шул исәптән:

- федераль законнарга туры китереп Спорт мәктәбе исеменнән гражданлык-хокукый килешүләр, хезмәт килешүләре төзи, Спорт мәктәбенең структурасын һәм штатларын раслый, Спорт мәктәбе хезмәткәрләренең вазифаи инструкцияләрен һәм бүлекчәләр турындагы нигезләмәләрне раслый;
- эшкә ала һәм эштән азат итә;
- ышанычнамәләр бирә;
- Спорт мәктәбенең барлык хезмәткәрләре өчен үтәлеше мәҗбүри булган боерыклар чыгара һәм күрсәтмәләр бирә;
- Оешманың финанс-хуҗалык планын, аның еллык һәм бухгалтерлык хисапларын, Оешма эшчәнлеген регламентлаштыручы эчке документларны раслый; Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгы Казначейство Департаментында счет ачуны тәэмин итә, Россия Федерациясенең салым турындагы законнарында каралган тәртиптә һәм күләмдә салым һәм җыемнарны вакытында түләүне тәэмин итә, билгеләнгән тәртиптә статистик, бухгалтерлык хисапларын һәм башка хисапларны тапшыра;
- Оешманың хокукый һәм башка локаль актларын имзалый, Оешма исеменнән ышанычнамә, шул исәптән башка кешегә ышанып тапшыру хокукы белән дә, бирә, боерык һәм карарлар чыгара, эш куша һәм Спорт мәктәбенең барлык хезмәткәрләре өчен үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирә;
- федераль законнарга туры китереп, вазифаи сер булырга тиешле мәгълүматның составын һәм күләмен билгели, шулай ук аны саклау тәртибен билгели һәм аны үтәүне тәэмин итә;
- Спорт мәктәбе эшчәнлегенең законлылыгын тәмин итә, Оешма бүлекчәләренең эшенә контрольлек итә һәм аларның үзара эффектлы эшләүләрен тәэмин итә;

үз компетенциясен гамәлгә ашыруга бәйле башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Директор күрсәтмәләре барлык хезмәткәрләр өчен дә мәҗбүри.

Оешма Директоры бурычлы:

а) муниципаль биремнең тулысынча үтәлешен тәэмин итү;

б) Оешма күрсәткән муниципаль һәм башка хезмәтләрнең, башкарган эшләрнең сыйфатын яхшырту буенча даими эш алып бару;

в) Гамәлгә куючы билгеләгән тәртиптә Оешманың финанс-хуҗалык планын тулысынча төзү һәм үтәлешен тәэмин итү;

г) Гамәлгә куючы билгеләгән тәртиптә оператив идарә итү өчен беркетелгән милектән файдалану турында Оешма эшчәнлеге буенча хисап төзүне тәэмин итү;

д) бюджет акчаларыннан, шул исәптән хезмәт күрсәтүгә (эш башкаруга) субсидияләрдән, башка максатларга субсидияләрдән макчатчан һәм рациональ файдалануны, Оешма тарафыннан федераль законнарга туры китереп финанс дисциплинасын үтәүне тәэмин итү;

е) эшләр башкару, хезмәт күрсәтү буенча килешү йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү;

ж) Оешманың срогында түләнмәгән бурычларын булдырмау;

з) Оешмага оператив идарә итү өчен беркетелгән милекнең сакланышын, файдаланылуын тәмин итү;

и) Оешма хезмәткәрләренә эш хакын вакытында түләүне тәэмин итү, Спорт мәктәбе хезмәткәрләренең эш хакын арттыру буенча чаралар күрү;

к) Гамәлгә куючы белән федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында, әлеге Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә Спорт мәктәбенең аңа оператив идарә итү өчен беркетелгән дәүләтнең күчемсез һәм аерым кыйммәткә ия күчемле милке белән идарә итүне, шул исәптән аңа хокукларны тапшыруны, шулай ук гамәлдән чыгаруны килештерү;

л) Оешма эре килешүләр төзегәндә Гамәлгә куючы белән, ул билгеләгән тәртиптә, алдан килештерү;

м) Төзелүенә ихтыяҗ булган һәм Оешма катнашында төзеләчәк килешүләрне Гамәлгә куючы белән килештерү;

н) Гамәлгә куючы белән федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарларында, Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә хуҗалык җәгыятьләренең устав (җыелма) капиталына Оешма тарафыннан акча кертүне (кертү шартлары буенча башкача каралмаган булса), аерым кыйммәткә ия күчемле милектән кала, милек кертүне яки гамәлгә куючы, катнашучы буларак милекне башка ысуллар белән тапшыруны килештерү;

о) Гамәлгә куючы белән федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында, әлеге Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә филиаллар ачуны һәм бетерүне, Оешманың вәкиллекләрен ачуны һәм ябуны килештерү;

п) Оешма, аның эшчәнлеге һәм аңа беркетелгән милек хакындагы мәгълүматның федераль законнар таләпләренә туры китереп ачык булуын тәэмин итү;

р) Оешма хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе һәм хезмәт дисципланасы Кагыйдәләрен үтәвен тәэмин итү;

с) Оешмада хезмәтне саклау һәм хезмәт куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тәэмин итү, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең һәм Оешма хезмәткәрләренең тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча федераль законнар таләпләренең үтәлүе өчен тиешле чаралар күрү;

т) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аттестация узу;

у) мобилизацион мөмкинлекләрнең булуын һәм гражданлык оборонасы таләпләренең үтәлешен тәэмин итү;

ф) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Оешма Уставында, Гамәлгә куючы карарларында билгеләнгән башка бурычларны үтәү.

5.6. Вазифаларын тиешенчә үтәмәү, дәүләт отчетын бозу өчен директор законнарда билгеләнгәнчә җавап тота.

5.7. Директор Оешма алдында эре килешүләр нәтиҗәсендә, мондый килешү гамәлдән чыгарылган дип саналу-саналмауга бәйсез рәвештә, Оешмага китерелгән зыян күләмендә җавап тота.

5.8. Директор Гамәлгә куючы белән килештереп директор урынбасарларын вазифага билгели.

5.9. Гомуми җыелыш Оешманың югары коллегиаль органы булып тора.

5.9.1. Гомуми җыелыш компетенциясенә керә:

1) Оешманы үстерүнең төп юнәлешләрен;

2) агымдагы эшчәнлекне һәм Оешманың үсешен тәэмин итү өчен финанс-хуҗалык эшчәнлегенең эффектлылыгын күтәрү, хезмәткәрләрнең хезмәтен стимуллаштыру, бюджеттан тыш акчалар кертү;

3) коллектив килешүне тикшерү һәм кабул итү;

4) Оешмада спорт әзерлегенең оптималь шартларын һәм формаларын булдыруга булышлык итү;

5) тиешле хезмәт шартларын үтәүгә, спорт әзерлеге үтүгә, тәрбияләнүчеләрнең сәламәтлеген саклау һәм ныгытуга контрольлек итү;

6) Оешма хезмәткәрләре арасыннан бүләкләнүгә лаеклы кандидатларны тикшерү һәм раслау.

5.9.2. Гомуми җыелыш составына керә: ата-аналар (аларның законлы вәкилләре), тәрбияләнүчеләр вәкилләре, Оешма хезмәткәрләре вәкилләре.

5.9.3. Гомуми җыелыш утырышлары кирәк булган чакта, кварталга бер мәртәбәдән дә сирәк булмаган вакыт аралыгында үткәрелә. Гомуми җыелыш утырышы, әгәр анда аның барлык әгъзаларының яртысыннан ким булмаган санда әгъзалары катнашса, карар кабул итәргә хокуклы булып санала.

5.9.4. Гомуми җыелыш карарлары ачык тавыш биреп, катнашучыларның гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

5.9.5. Утырышны алып бару өчен Гомуми җыелышның рәисе һәм сәркәтибе сайлана. Гомуми җыелыш һәм ул кабул иткән карарлар беркетмә рәвешендә теркәлә. Беркетмәне рәис һәм сәркәтип имзалый.

5.11. Тренерлар советы Оешмада үзидарәнең даими эшләүче органы булып тора. Ул Оешма һәм спорт әзерлеге эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләрне карау өчен төзелә.

5.11.1. Тренерлар советы чикләнмәгән срокка төзелә һәм Тренерлар советы турындагы нигезләмәгә таянып эш итә.

5.11.2. Тренерлар советы әгъзалары булып Оешманың тренерлары һәм эшчәнлекләре спорт әзерлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру белән турыдан туры бәйле башка хезмәткәрләр тора. Тренерлар советының рәисе булып Оешма директоры исәпләнә..

5.11.3. Тренерлар советы:

1) спорт төрләре һәм әзерлек этаплары буенча спорт әзерлеге программаларын карап тикшерә;

2) тренерларның квалификациясен күтәрү, алдынгы спорт тәҗрибәсе белән уртаклашу, тренерларны аттестацияләү эшләрен оештыра;

3) спорт әзерлеге узучы затларны әзерлекнең алдагы этабына күчерү мәсьәләләрен карый;

4) спорт әзерлеген оештыру мәсьәләләре комплексын карап тикшерә;

5) спорт әзерлеге узучы затларны Оешмадан чыгару мәсьәләләрен карый;

6) Тренерлар советы турындагы нигезләмәдә каралган башка мәсьәләләрне чишә.

5.11.4. Тренерлар советы тулы составта кирәк булганда, кварталга бер мәртәбәдән дә сирәк булмаган вакыт аралыгында җыела. Агымдагы мәсьәләләрне карау өчен Тренерлар советы чираттан тыш җыелырга мөмкин.

5.11.5. Решения Тренерлар советының үз компетенциясеннән чыгып кабул иткән карарлары, әгәр утырышта аның барлык әгъзаларының яртысыннан ким булмаган санда әгъзалары катнашса, хокуклы булып санала. Карарлар гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә формасында рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда Тренерлар советы рәисенең тавышы хәлиткеч булып исәпләнә.

## VI. ОЕШМАНЫҢ МИЛКЕ ҺӘМ АНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕН ФИНАНС БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

6.1 Оешмага милек Гамәлгә куючы (Милекче) тарафыннан оператив идарә хокукы белән беркетелә. Милекне аерым кыйммәткә ия күчемле милек категориясенә кертү турындагы карар Оешмага милек беркетү турындагы карар белән бер вакытта кабул ителә.

6.2. Оешмага үз Уставы максатларын үтәү өчен кирәк булган җир кишәрлеге аңа даими (срогы чикләнмәгән) файдалану хокукы белән бирелә.

6.3. Оешма үзенә беркетелгән милектән файдалану һәм аның белән идарә итү хокукын законнарда билгеләнгән чикләрдә гамәлгә ашыра.

6.4. Милекче ризалыгыннан башка Оешманың үзенә Милекче тарафыннан беркетелгән яки Гамәлгә куючы тарафыннан милек сатып алуга бүленеп бирелгән акчага сатып алынган аерым кыйммәткә ия күчемле милек, шулай ук күчемсез милек белән идарә итүгә хокукы юк. Оператив идарә хокукындагы калган милек белән, Уставта һәм законнарда башкача каралмаган булганда, Оешма мөстәкыйль идарә итәргә хокуклы.

6.5. Оешманың милке һәм финанс ресурслары формалашу чыганаклары булып торалар:

- аңа оператив идарә хокукында беркетелгән милек;
- Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан муниципаль хезмәт күрсәтү, эшләр башкару буенча муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өчен бүленеп бирелгән субсидияләр;

- Чүпрәле муниципаль районы Советының тиешле финанс елына район бюджеты турындагы карары белән муниципаль хезмәт күрсәтү, эшләр башкару буенча муниципаль биремне үтәү белән бәйле булмаган максатларга бүленеп бирелгән субсидияләр (максатчан субсидияләр);

- табыш китерүче эшчәнлектән килгән акчалар;

- спонсорлардан кергән акчалар һәм гражданнарның ирекле иганәләре;

- гамәлдәге законнарда тыелмаган башка чыганаклар.

6.6. Оешманың милек һәм акчалары аның балансында чагылдырыла һәм Устав билгеләгән максатларга ирешү өчен кулланыла. Оешмага беркетелгән яки Гамәлгә куючы тарафыннан милек сатып алуга бүленеп бирелгән акчага сатып алынган күчемсез милек, шулай ук Оешмада булган аерым кыйммәткә ия күчемле милек билгеләнгән тәртиптә аерым хисапланырга тиешләр.

6.7. Табыш китерүче эшчәнлектән килгән акчалар, шулай ук Россия һәм чит ил юридик һәм физик затларыннан иганә рәвешендә кергән акчалар һәм бу акчалар хисабына сатып алынган милек Оешманың мөстәкыйль идарәсенә күчә.

6.8 Оешма коммерциячел булмаган оешмаларга аларны гамәлгә куючы яки катнашучы сыйфатында акчаны (аларны бирү шартларында бүтәнчә каралмаган булса) һәм башка милекне, Милекче тарафыннан беркетелгән яки Гамәлгә куючы тарафыннан милек сатып алуга бүленеп бирелгән акчага сатып алынган аерым кыйммәткә ия күчемле милектән, шулай ук күчемсез милектән кала, бары тик Гамәлгә куючы һәм Милекче ризалыгы белән генә тапшыра ала..

6.9. Оешма хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек нәтиҗәләре буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә салым исәп-хисабы, оператив бухгалтерлык исәп-хисабы һәм статистика исәп-хисабы алып бара..

Оешма ел саен Гамәлгә куючыга күчемсез милекне һәм Оешманың үзенә Милекче тарафыннан беркетелгән яки Гамәлгә куючы тарафыннан милек сатып алуга бүленеп бирелгән акчага сатып алынган аерым кыйммәткә ия күчемле милекне карап торуга киткән чыгымнар, тиешле милек һәм җир кишәрлеге буенча салым түләү объекты буларак салым түләү чыгымнары, билгеләнгән тәртиптә расланган программалар кысаларында Оешманы үстерүне финанс ягыннан тәэмин итүгә чыгымнар исәп-хисабын тапшыра..

6.10. Оешманың акчаларны кредит оешмаларында депозитларга куярга, кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-биреш ясарга, әгәр федераль законнарда башкача каралмаган булса, хокукы юк.

## VII. СПОРТ ӘЗЕРЛЕГЕ ҮТҮ ӨЧЕН ОЕШМАГА КАБУЛ ИТҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ.

7.1. Спорт әзерлеге үтү өчен Оешмага кабул итү Гамәлгә куючы тарафыннан расланган муниципаль бирем күрсәткечләренә туры китереп, спортның аерым төре буенча шөгыльләнергә сәләтне бәяләп, шулай ук әлеге спорт төре белән шөгыльләнергә каршылыклар булмаганда гамәлгә ашырыла.

Оешма тарафыннан заказчылар белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры китереп төзелгән килешүләр нигезендә Оешма расланган муниципаль биремнән тыш түләүле спорт әзерлеге үтү өчен кешеләр кабул итәргә хокуклы.

7.2. Беренче елның башлангыч әзерлек этабына гаризалар “Интернет” информацион-телекоммуникацияләр челтәрендәге “Татарстан Республикасында электрон мәгариф” системасында edu.tatar.ru Порталы аша Порталда теркәлү узучылар электрон гариза тутырып, шулай ук Оешманың үзендә бирелергә мөмкин.

7.3. Оешмага кабул итү муниципаль хезмәт күрсәтүгә (эш башкаруга) расланган муниципаль биремгә туры килгән урыннар санына гамәлгә ашырыла.

7.4. Төркемнәрнең минималь тулылыгы, шөгыльләнүчеләрнең яше, спорт әзерлеге этапларында физик культура һәм спорт буенча тренировка дәресләренең озынлыгы, шулай ук тренерлык йөкләнеше спорт төрләре программаларында билгеләнә. Спорт әзерлеге этаплары өчен бу күрсәткечләр спорт төрләре буенча спорт әзерлеге Федераль стандартлары таләпләренә туры килергә тиеш.

7.5. Оешмага кабул итү физик культура һәм спорт буенча дәресләр төркемнәренә һәм спорт әзерлегенең агымдагы елдагы этапларына башкарыла.

7.6. Оешмага кабул итү, индивидуаль сайлап алу һәм Оешмага билгеләү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

- физик культура һәм спорт буенча дәресләр төркемнәренә (мондый төркемнәр булганда) гомуми нигездә, балигъ булмаган гражданнар арасыннан, спорт белән шөгыльләнүгә тотрыклы кызыксыну формалаштыру һәм спорт әзерлеге үтү өчен сайлап алу максатында;
- башлангыч әзерлек төркемнәренә (мондый төркемнәр булганда) балигъ булмаган гражданнар арасыннан, спорт әзерлеге Федераль стандартларында һәм Оешмада расланган спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программаларында билгеләнгән индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре нигезендә;
- әзерлекнең тренерлык этабы (спортта махсуслашу этабы) төркемнәренә алдагы этапта (башлангыч әзерлек этабында) спорт әзерлеген уңышлы узган, сайланган спорт төре буенча сәләтен күрсәткән, контроль-күчеш (кабул итү) нормативларын һәм спорт төрләре буенча спорт әзерлеге Федераль стандартларына туры килгән спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программалары таләпләрен үтәгән затлар арасыннан;
- спорт осталыгын үстерү һәм югары спорт осталыгы төркемнәренә спорт әзерлеге Федераль стандартлары нигезендә әзерлекнең индивидуаль планнарын үтәү, төрле дәрәҗәдәге спорт ярышларында тотрыклы уңышлы чыгыш ясау нигезендә.

7.7. Керергә теләүчеләргә максималь күләмдә мәгълүмат бирү максатында Оешма үзенең мәгълүмати стендларында һәм Интернет информацион-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

- спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программалары күчермәләрен;

- спорт төрләре буенча Оешмага керү өчен минималь яшькә карата таләпләрне;

- кабул итү комиссиясенең эш расписаниесен;

- спорт әзерлегенең һәр этабы буенча буш урыннар турындагы мәгълүматны;

- Оешмага керү өчен документлар тапшыру сроклары турындагы мәгълүматны;

- Оешмага керү өчен гомуми физик әзерлек һәм спорт төрләре буенча махсус физик әзерлек нормативларын;

- шәхси сайлап алулар үткәрү графигын;

- сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны;

- Оешмага кабул итү өчен кабул итү комиссиясе тәкъдим иткән затларның исемлеген;

- сайлап алу нәтиҗәләре буенча апелляция бирү кагыйдәләрен.

7.8. Оешма тарафыннан заказчылар белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры китереп төзелгән килешүләр нигезендә Оешма расланган муниципаль биремнән тыш түләүле спорт әзерлеге үтү өчен кешеләр кабул итәргә хокуклы.

7.9. Буш урыннар булганда Оешмага кабул итү һәм төркемнәрне тулыландыру агымдагы ел (тренировка елы) барышында башкарылырга мөмкин.

7.10. Керүчеләрне кабул итү тәртибе Оешманың локаль актында билгеләнә һәм сайлап алу нәтиҗәләре буенча кабул итү комиссиясе карары нигезендә чыгарылган Оешма директоры боерыгы белән рәсмиләштерелә.

## VIII. МӘНФӘГАТЬЛӘР КОНФЛИКТЫН БУЛДЫРМАУ ҺӘМ ҖАЙГА САЛУ

8.1. Мәнфәгатьләр конфликты дип Оешма хезмәткәренең шәхси мәнфәгатьләре аның хезмәт вазифаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаганда һәм бу вакытта Оешма хезмәткәренең шәхси мәнфәгатьләре белән ул эшләгән Оешманың хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Оешма милкенә һәм (яки) аның эшлекле репутациясенә зыян салырдай каршылыклар килеп чыкканда яки килеп чыгарга мөмкин булганда барлыкка килгән вәзгыять кабул ителә.

8.2. Оешма хезмәткәренең аның хезмәт вазифаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаучы яки ясарга мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләре дип Оешма хезмәткәренең хезмәт вазифаларын башкаруына бәйле рәвештә үзенә яки башка затларга акчалата керем, байлык, башка милек, шул исәптән милеккә хокук яки милеккә кагылышлы хезмәтләр алуы мөмкин булган мәнфәгатьләре кабул ителә.

8.3. Оешма директоры вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына алып баручы яки алып баруы мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе хакында хезмәткәрләргә хәбәр итәргә бурычлы.

8.4. Оешма хезмәткәре вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына алып баручы яки алып баруы мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе хакында Оешма директорына хәбәр итәргә бурычлы. Хәбәр итү тәртибе, хәбәрләрдә булырга тиешле мәгълүматлар исемлеге, бу мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе Оешма директоры тарафыннан билгеләнә.

## IX. ОЕШМАНЫ ҮЗГӘРТЕП ТӨЗҮ, ТИБЫН ҮЗГӘРТҮ ҺӘМ БЕТЕРҮ

9.1. Оешма Россия Федерациясе Гражданлык Кодексында, федераль законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә үзгәртеп төзелергә мөмкин.

9.2. Оешманы үзгәртеп төзү түбәндәге формаларда гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- ике яки берничә учреждение кушылып;
- Оешмага охшаш милек формасы булган ике яки берничә учреждениене кушып;
- Оешма охшаш милек формасы булган ике яки берничә учреждениегә бүленеп;
- Оешмадан охшаш милек формасы булган ике яки берничә оешма бүленеп чыгып.

9.3. Оешма кушылу һәм кушу формасында, әгәр күрсәтелгән процесста катнашучылар бер үк милекче милке базасында төзелгән булса, үзгәртеп төзелергә мөмкин.

9.4. Оешманың тибын үзгәртү федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9.5.Оешма Россия Федерациясе Гражданлык Кодексында каралган нигеләрдә һәм тәртиптә берелергә мөмкин.

9.6. Бетерелүче Оешмага карата кредиторлар таләпләре законнарга туры китереп алынырга мөмкин булган милек хисабына үтәлә.

9.7. Кредиторлар таләпләрен үтәгәннән соң калган, шулай ук федераль законнарга туры китереп Оешма йөкләмәләре буенча алынуы мөмкин булмаган Оешма милке ликвидация комиссиясе тарафыннан Милекчегә тапшырыла.

## X. УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ

Оешма Уставына кертелүче үзгәреш һәм өстәмәләр юридик затларга дәүләт теркәве үткәрүче органда теркәлгән моменттан үз көченә керә.

Оешманы гамәлгә кую документларындагы үзгәрешләргә дәүләт теркәве законнар билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.